ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«06» сентябрь 2021 ел № 296

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 3 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең арадаш ликвидация балансын раслау турында

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 63 статьясы, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 3 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен бетерү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23 мартындагы 73 номерлы карары нигезендә, ликвидация чаралары үткәрелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 3 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең арадаш ликвидация балансын (дәүләт (муниципаль) учреждениесе балансы) расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 3 нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең арадаш ликвидация балансын (дәүләт (муниципаль) учреждениесе балансы) раслау турында» 2021 елның 28 июлендәге 232 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**